ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 26.12.2024 2214 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә социаль челтәрләр мониторингы төркеме «Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы» төзү турында» 2023 елның 13 гыйнварындагы 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 ноябрендщге 438-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә социаль челтәрләр мониторингы төркеме «Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы» төзү турында» 2023 елның 13 гыйнварындагы 21 номерлы карары белән расланган «Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы» социаль челтәрләр мониторингы төркеме турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балаларда наркотик чаралар, психотроп һәм (яки) аңын томалый торган матдәләр, тәмәке әйберләре, никотинлы продукция, көнкүреш билгеләнешендәге потенциаль куркыныч газлы товарларда булган сыекландырылган углеводород газлары һәм (яисә) аларның парлары, алкоголь һәм спиртлы продукция, сыра һәм аның нигезендә җитештерелә торган эчемлекләр куллану, комарлы уеннарда катнашу, сукбайлык яки теләнчелек белән шөгыльләнү теләге уятырга сәләтле;».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Н.Д .Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 15.10.2023 до 11.01.2025



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН